**1. Оештыру-мотивлаштыру** (2минут)

Җыйдым әле бер шакмакка
Кояшның якты нурын.
Салдым анда өстәп тагын
Язгы һава сафлыгын.

Күңелемдәге ак хисләрне.
Алып килдем монда мин.
Яхшы кәеф төсен дә
Сезгә бүләк итәмен.

Дәрес буе ул сезгә
Эшкә дәрт биреп торсын.
Минеке кебек сезнең дә
Кәефегез шәп булсын! *(төркемнәргә шакмаклар бирәм)*

- Укучылар, бу нәрсә? *(Үлчәү)*

- Дөрес, укучылар, бу весы. Ә татарчасы бик матур сүз белән үлчәү дип атала.

- Экранда сез берничә төрле үлчәү күрәсез. Игътибар итсәтег бу сүзнең кушымчасы башка төс белән күрсәтелгән. Моның ни өчен шулай булуын дәрес барышында белербез.

- Нинди һөнәр ияләре куллана?

- Әлеге сорауга җавапны без дәрес барышында белербез.

- Үлчәү белән нәрсә эшлиләр соң? (Үлчиләр)

- Ә кәефне үлчәп буламы соң?

- Мин сезнең белән килешәм.

- Без моны дәрес ахырында белербез.

**2. Актуальләштерү** (3минут)

- Һәр төркемдә карточкалар бар. Аларны нинди сүз төркемнәренә бүлеп була икән?

- Хәзер әйдәгез шушы карточкадагы сүзләрне ике төркемгә бүлегез дә берегез тактага элегез.

- Дөрес, укучылар. Биредә исемнәр һәм фигыльләр язылган.

- Хәзер сүзләрнең кушмчаларына карап исем сүз төркеме турында белгәннәрне искә төшерик.

- Фигыль турында без нәрсәләр беләбез соң?

**3. УМК** (2 минут)

- Димәк, укучылар, без бүген дәрестә нәрсә турында сөйләшербез? *(Исем фигыль)*

- Әйе, дәресебезнең темасы затланышсыз фигыль төркемчәсе “Исем фигыль”. Теманы эш кәгазьләренә язып куегыз.

- Укучылар, бүгенге дәресебезгә нинди максат куябыз?

- Әйдәгез бу шакмакны билгесезлек дип атыйк. *(Сораулар язылган шакмак үлчәүгә куела)*

- билгесезлек шакмагындагы сорауларга җавап биргән саен төркемдәге кәеф шакмакларыбызның якларын тулыландырып барырбыз.

**4. УМЧ**

1нче эш (3 минут)

- Укучылар, бу нәрсә? *(Уймак, киерге, каурый)*

- Уйлагыз әле, бу әйберләрне нинди һөнәр ияләре куллана?

- Мин һәр төркемгә бер предмет бирәм.

- Бу предметлар белән эшбашкаргач, нәрсә барлыкка килә? *(Тегү, чигү, язу) – күрсәтелә.*

- Болар халкыбызның борынгы һөнәрләре.

- Болар нинди сүзләр? *(Исем фигыльләр)*

- Исем кебек алар эш-хәлнең нәрсәсен белдерәләр? *(исемен)*

- Ә фигыль кебек нәрсәне белдерәләр? *(эш-хәлне)*

- Дөрес укучылар. Димәк, исем фигыль исем кебек эш-хәлнең исемен, ә фигыль кебек эш-хәлне белдерә икән. Хәзер әйдәгез эш кәгазьләрендәге 1нче биремне эшләгез.

- Экранга карап җавапларыгызны тикшерегез.

- Әлеге җавабыбызны да шакмакның бер ягына ябыштырыйк.

2нче эш (2 минут)

- Укучылар, һәр төркемдәсүзләр һәм кушымчалар язылган кәгазьләр бар. Сезгә алардан исем фигыльләр төзергә һәм тактага беркетергә кирәк. Бу эшне каршыгызда утырган иптәшегез белән эшләгез. *(Тактага эләләр)*

- Укучылар, тактадагы исем фигыльләргә игътибар итегез әле, ни өчен кайбер кушымчалар зәңгәр, кайберләре кызылсары, ә кайберләре ал төстә икән?

- Исем фигыльне нинди кушымчалар ярдәмендә ясадык соң? *(-у, -ү, -ю)*

- Нинди сүзләргә без –у кушымчасын ялгыйбыз? *(Калын сүзләргә)*

- Нинди сүзләргә без –ү кушымчасын ялгыйбыз? *(нечкә сүзләргә)*

- Нинди сүзләргә без –ю кушымчасын ялгыйбыз? *(сузыкка беткән сүзләргә)*

- Димәк, укучылар, исем фигыльләр калын сүзләргә -у, нечкә сүзләргә -ү, сузыкка беткән сүзләргә -ю кушымчасы ялганып ясала икән.

- Хәзер эш кәгазьләрегездә 2нче таблицаны тутырып куегыз.

- экранга карап җавапларыгызны тикшерегез, үзбәя куегыз.

- һәм инде, укучылар, әлеге нәтиҗәне үзебезнең шакмакка беркетеп куйыйк.

<u>3нче эш</u> (4 минут)

- Укучылар, хәзер үзегезнең төркемдәге предметка туры килгән рәсем янына барырсыз. Рәсем артына ребус яшерелгән аны сезгә бергәләп чишәргә кирәк. *(3 төркемдә 3 төрле исем фигыль)*

- Килеп чыккан фигыльне эш кәгазьләренә язып куегыз һәм аны мәгънәле кисәкләргә таркатып таблицага урнаштырыгыз.

- Укучылар, таблицаның исем сүз төркеменә туры килгән өлешләрен гади карандаш ярдәмендә авыш сызыклар белән билгеләгез.

- укучылар, исем фигыль исемнәр кебек нәрсәләр белән төрләнә ала икән? *(сан, тартым, килеш)*

- Исем фигыльнең фигыльләр белән нинди уртак яклары бар? *(барлык, юклык формасы)*

- Эшләрегезне яныгызда утырган иптәшегез белән алмашыгыз да экранга карап тиешерегез. Үзбәя куегыз.

- Димәк, исем фигыльләр исем кебек сан, тартым, килеш белән, ә фигыль кебек барлык-юклык формасы һәм юнәлеш белән төрләнә алалар икән.

- һәм шакмака бу нәтиҗәне дә өстәгез.

<u>4нче эш</u> (3 минут)

- Укучылар, эш кәгазьләрендәге 4нче биремгә игътибар итегез. Сезгә бирелгәнсхемага туры китереп җөмлә төзергә кирәк. Эшне башкару өчен 2 минут вакыт бирелә. Һәркем биремне үзе эшли.

- ..., 1нче схемага төзегән җөмләңне укы әле.

- исем фигыль нинди җөмлә кисәге булып килгән? *(ия)*

- исем фигыль нинди җөмлә кисәге булып килгән? *(тәмамлык)*

- исем фигыль нинди җөмлә кисәге булып килгән? *(аергыч)*

- исем фигыль нинди җөмлә кисәге булып килгән? *(хәл)*

- исем фигыль нинди җөмлә кисәге булып килгән? *(хәбәр)*

- Димәк укучылар, исем фигыль җөмләнең нинди кисәкләре булып килә ала? *(ия, тәмамлык, аергыч, хәл)*

- Әйе, исем фигыль җөмләдә ия, тәмамлык, аергыч, хәл булып килә ала?

- бу нәтиҗәбезне дә шакмакка урнаштырып куйыйк.

<u>Видео</u> (2 минут)

- укучылар, мин хәзер сезгә видеоязма кушам. Сез аны игътибар белән карагыз һәм күргәннәрегезне исем фигыльләр белән әйтеп барыгыз.

- әлеге мультфильм нинди һөнәр турында иде? (төзүче)

- Танышларыгыз арасында төзүчеләр бармы?

- Сезнең арада да төзүче булырга теләүчеләр бармы укучылар?

- Нинди генә һөнәр сайласагыз да ул сезнең күңелегезгә хуш килсен. Мин сезгә үзегез яраткан һөнәр ияләре булуыгызны телим.

**5. Рефлексия (3 минут)**

- укучылар, дәрес башында без үлчәүгә билгесезлек шакмагын салган идек. Мин төркемнәргә тараткан кәеф шакмаклары ярдәмендә сез дәрес буе бик тырышып эшләдегез. Дәрес башында кәефне үлчәп буламы дип сораган

идек. Әйдәгез хәзер кәефебезне үлчәп карыйк инде. Моның өчен мин һәр төркемдә сораулар язылган шакмакны ыргытам. Нинди сорау өскә карап кала, төркем шул сораугa җавап бирергә тиеш була.

- җавап биргән саен кәеф шакмагын үлчәүнең бер як тәлинкәсенә салып барырсыз.

*(һәр җавап саен укучылар төркемдәге шакмакны үлчәүгә салалар)*

- Рәхмәт, балалар. Күргәнегезчә, бүгенге дәрестә безнең яхшы кәефебез өстенлек алды.

- хәзер эш кәгазьләрегездә үзегезгә билгеләр куегыз.

- кемнәр, үзләренә бишле куйдылар? 4, 3? *(укучыларны бастырып алу)*

- Өй эше эш кәгазьләрендә язылган. Дәрес тәмам укучылар, сораулар булмаса, чыгарга мөмкин. Рәхмәт.